# Нәсыйхәт

җомга 27 июль 2012 №16

Рәхимле вә Шәфкатьле АЛЛАҺ исеме белән
Мамадыш мәдрәсәсенең айлык дини-иҗтимагый газетасы


Мөхәррир сүзе

# Сынау, сабырлык ае



**Хөрмәтле районлашлар, мөселман кардәшләр! Мамадыш мәдрәсәсе коллективы һәм газетабызның редакциясе исеменнән сезне вә бөтен мөселман кардәшләребезне 2012нче елның Рамазан ае башлану белән ихлас күңелдән тәбрик итәм.**

Аллаһ Раббыбызга сансыз мактау вә хамде-сәнәләребез булсын. Унике айның солтаны булган Рамазан-Шәриф аена ирештереп гөнаһлардан пакъланырга, Үзенең ризалыгын казанып, хәерле изге гамәлләр кылып, күп савапларга ирешергә тагын бер мөмкинчелек бирде.

Бу ай мөселманнар арасында ярдәмләшү һәм ризыкның бәрәкәтле вә мул булган аедыр. Кем бу айда бер уразалы кешене ифтар кылдырса бер кол азат иткән кадәр савап казаныр һәм дә бөтен гөнаһларының гафу ителүенә сәбәп булыр. Пәйгамбәр әфәндебезнең иң бөек могҗизасы булган Коръән-Кәрим бу айда иңдерелгәне өчен, бу айда изге китабыбызны уку һә аны укып чыгу яки хәтем кылу зур әҗерле гамәллләрдән санала. Газиз кардәшләребез! Рамазан шәриф аенда мәчетләрдә, тәравихларда, мәҗлесләрдә хаҗәт намазлары укып, Аллаһтан шифалы яңгырларын сорыйк, хәерле, бәрәкәтле тормыш үтеник, илләребезгә хәерле тынычлыклар ялварыйк. Раббыбыз шәт Рамазан ае, Коръән иңгән ай хөрмәтенә догаларыбызны кабул итәр. Рамазан ае бер яктан –күңелгә шатлык, икенче яктан җаваплылык өсти. Шатлык, чөнки Аллаһының рәхмәтенә якынаябыз, җаваплылык, чөнки билгеле булганча, һәр башланган әйбернең ахыры бар. Димәк безгә күп кенә бүләкләр белән килгән кадерле кунагыбызны озатыр вакытлар да көттермәс. Шуңа күрә үкенечкә калмасын өчен Рамазан ае биргән бик күп кыйммәтле дәресләрне тормышыбызга ашырсак иде. Шушы дәвердә нәфесебезне җиңәргә, күңелне пакълэргә, хайван сыйфатларын җиңәргә өйрәнсәк иде. Рамазан ае безгә юмартлык дәресләрен дә бирмичә калмас. Шунлыктан Раббыбызның ачуын китерә торган саранлыгыбыздан арынсак иде. Хөрмәтле кардәшләр! Раббыбыз тоткан уразаларыбызны, кылган изгелекләребезне кабул итсен! Киләчәк Рамазан аен да исәнлектә каршы алып, уразаларны тотарга насыйп итсә иде!

**Габдрахман хәзрәт ХӘБИБУЛЛИН**

## Район яңалыклары

### ЯҢА УКУ ЕЛЫНА ӘЗЕРЛЕК

**Мәдрәсә бинасында яңа уку елына әзерлек бара.** Уку җиһазлары ремонтлана, буяу һәм чистарту, уку бүлмәләрен төзеклəндерү эшләре алып барыла. Авырлыкларга карамыйча, бу эшләрне мәдрәсә үз көче белән башкара.

### МӘДРӘСӘ– ДИНИ ҮЗӘК ТӘ

**Мамадыш мәдрәсәсе уку йорты вазыйфасын гына алып бару белән чикләнми, бәлки дини үзәккә әверелә бара.** Мәдрәсә базасында күп санлы дини чаралар үтә: авыл имамнары җыелышлары уздырыла, җәйге балалар җәйләүләре киң колач җәеп үткәрелеп килә, төрле мәҗлесләр, бәйрәм тантаналары оештырыла. Рамазан аенда да ифтарлар көтелә. Ифтар үткәрергә теләүчеләр түбәндәге телефон аша мөрәҗәгать итә алалар: 89172802391

### АУДИТ ТИКШЕРҮЕ ҮТТЕ

**16 нчы июль көнне мәдрәсәдә аудит тикшерүе үтте.** Казан шәһәреннән килгән голәмәләр шурасы рәисе Рөстәм хәзрәт Батыров җитәкчелегендәге махсус комиссия уку-укыту документларын тикшерде, укытуны оештыру эшләре белән танышты. Тикшерү азагында комиссия вәкилләре үзләренең тәкъдимнәрен һәм киңәшләрен җиткерделәр.

### КАБУЛ ИТҮ КОМИССИЯСЕ ЭШЛИ

**Мәдрәсәгә укырга керергә теләүчеләр өчен кабул итү комиссиясе эшли.** Бирердә уку-укытуга кагылган сорауларга җавап бирәләр, документларны, белешмәләрне кабул итәләр. Белешмәләр өчен телефон: 89172802391,

### МӘДРӘСӘ МӨГАЛЛИМНӘРЕ– ИФТАРЛАРДА

**Мәдрәсә мөгаллимнәре районның төрле авылларында уза торган ифтар мәҗлесләрендә актив катнашыр дип көтелә.** Мәҗлесләр барышында алар килгән халыкның сорауларына җавап бирәчәкләр һәм аларга файдалы вәгазь-насыйхәтләрен җиткерәчәкләр.

### МӘДРӘСӘГӘ БИРЕРГӘ МӨМКИН

**Мәдрәсәдә яңа уку елына әзерлек бара**.

Ел дәверенә шәкертләргә җитәрлек ризык туплау, укытучыларга хезмәт хакы түләү өчен финанс булдыру гаять дәрәҗәдә авыр хезмәт. Шуңа күрә мәдрәсә халыкның ярдәменә мохтаҗ. Хөрмәтле районлашлар, мәдрәсәбезнe ятим итмик, гыйлем йортына гошер һәм фитра сәдакалары белән ярдәм итик.

# РАМАЗАН АЕ МӨБАРӘК БУЛСЫН!

**Хөрмәтле мөселман кардәшләр!**
Әссәләмегаләйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһү!

Безне һидәяткә күндергән, куңелләребезгә иман нурын иң зиннәтле нәрсә итеп урнаштырган Аллаһы Тәгаләгә барча мактауларыбыз булсын. Пәйгамбәребезгә рәхмәт-салаватларыбыз, сәхәбәләренә, аңа изгелектә иярүчеләргә догаларыбыз барып ирешсен.

Агымдагы елыбызның 19 июль кичендә, дөньябызның һәр почмагында яшәгән мөселманнар өчен мөбарәк Рамазан ае керде. Әлеге җан-тән гыйбәдәте ае булган ураза ае 18 август ахшамына кадәр дәвам итәчәк. Изге Рамазан ае башлану – бөтен дөнья мөселманнары өчен шатлык һәм шул ук вакытта җаваплылыкны аңлап каршы алынучы вакыйга да. Бу айда һәрберебез Аллаһы Тәгаләдән гөнаһларыбызны гафу итүне, ярлыкауны сорый, Аның рәхим-шәфкатенә өметләнә. Мөселманнарыбыз үзләре дә изгелекләр эшләргә омтыла.

Әйе, мөбарәк Рамазаныбыз килеп җитте. Аллаһы Тәгалә Коръәндә әйтте: «И, иман китергән бәндәләрем, сәламәт, гайрәтле, көчле, куәтле, акыллы хәлегездә Рамазан аена ирешсәгез, ураза тотыгыз». Барчаларыгызны шушы мөбарәк айга керүегез белән ихластан котлыйбыз. Ураза ае –мөселманнар өчен аерым бер гыйбадәт, Аллаһыны тану-белү, аңа итагать итү ае. Бу айда нәфесебезне тәрбияләп, без Раббыбызга якынаябыз, рәхмәтенә ирешәбез. Динебез Исламда Рамазан аенда ураза тоту биш баганаларның берсе санала. Бу ай чын мәгънәсендә безгә бихисап күп дәресләр бирүче мәдрәсәгә тиң. Бигрәк тә бу мөбарәк ай дәверендә безгә гөнаһлардан тыелу зарур. Чөнки Пәйгамбәребез с.г.в . әйтте ки: “Кем яла ягуны, бозыклык сөйләүне һәм шундый гамәлләр кылуны ташламаса, белсен, ул кешенең азыктан тыелуында әҗер юктыр”. Әйе, кеше иң элек үзенең уй-фикерләрен, ниятен, кылган гамәлләрен кайгыртырга тиеш. Рамазан ае безгә рухыятебезне аңларга, иманнарыбызны ныгытырга, рухи байлыгыбызны арттырырга ярдәм итә. Чөнки, әгәр дә җәмгыятьтә рухи әхлаксызлык, рәхимсезлек тамыр җәя һәм кеше бу җиргә ни өчен килгәнен аңламау дәрәҗәсенә төшә икән, бернинди дә матди байлык мөһим булмаячак.

Рамазан–гафу итү ае. Пәйгамбәребез с.г.в. безгә Кадер кичәсендә укыла торган шушы доганы: «Әллааһүммә әнтә гәфүвүн. Түхиббүл гәфвә. Фәгфү гәннәә». «Йә, Раббым, Син Гафу Итүче Зат, гафу итүне сөясең. Гөнаһларыбызны гафу ит» юкка гына өйрәтмәде.

Пәйгамбәребез с.г.в. әйтте: «Кем Рамазанда тәкъвалык белән ураза тотса, аның моңа кадәрге булган барча гөнаһлары ярлыканыр».

Шуңа күрә, тормыш вакыйлары белән, моңа кадәр бер-беребезгә булган ачу, үч, нәфрәтләребезне Рамазанның тышында калдырып, бер-беребезне гафу итик. Моңа кадәр туган-туганы, дусты- кардәше белән араларыбызны өзгән булсак, яңартыйк. Кардәшлек, туганлык, мөселманның берберенә булган хакларын, ата-ана хакын, бала хакын, ир-хатын хакын, күршелек хакларын искә алып, хаклыйк.

Берсүзсез, үзен мөэмин-мөселман дип санаган һәр кеше Рамазан аен шатланып, шөкер итеп каршылый. Сөенечнең беренчесе –ифтар вакытында авыз ачканда, икенчесе – кыямәт көнендә Раббысы каршында. Ә Аллаһы Тәгалә тарафыннан бирелгән күркәм вәгъдәләрнең иң зурысы: “Рамазан аенда ураза тотучының тоткан уразасы кабул булса, анадан яңа туган бала шикелле гөнаһсыз булып калыр”, – диелгән Рәсүлебезнең хәдис-шәрифендә. Бу бик зур сөенеч. Билгеле булганча, адәм баласы әйбер юкка чыккач кына аның кадерен белә. Шулай ук авыру кеше дә сау кешегә караганда сәламәтлекнең кадерен яхшырак аңлый, шунлыктан ураза тоту һәр кешене уйландырырга мәҗбүр итә. Бүгенге көндә шунысы сөендерә, ураза тотучыларның саны арта бара. Бик күпләр нәкъ менә әлеге фарыз гамәл аркылы динне тулысынча кабул итә. Бу аңлашыла да, чөнки үзенең ихтыяр көчен ураза тотуга буйсындырган кеше башка сынаулар алдында да бирешми. Быел Ураза җәйнең аеруча озын көннәренә туры килә. Бу да Ходай Тәгаләнең безне сынавы. Әмма, Аллаһы Тәгаләнең юллаган сынаулары безне тагын да акыллы һәм нык булырга өйрәтә. Без бернигә дә карамый, Аллаһы Тәгаләнең риза-

## Дөньяда ниләр бар?

### “ХӘЛӘЛ” КОМИТЕТЫ ТАРАФЫННАН СЕРТИФИКАЦИЯЛӘНГӘН ПРЕДПРИЯТИЕЛӘР ИСЕМЛЕГЕ ТУЛЫЛАНДЫРЫЛДЫ

*Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте карамагындагы “Хәләл” стандарты комитеты тарафыннан сертификацияләнгән предприятиеләр реестры тулыландырылды.*

Яңа предприятиеләр арасында Казанның ит ризыклары җитештерү белән шөгыльләнүче “Юлдаш” фирмасы һәм Яшел Үзән шәһәренең ипи һәм камыр ризыклары пешерүче “Кондитер” оешмасы бар.




Шулай ук сертификация вакыты чыккан предприятиеләр дә яңадан тикшерелгән. “Ставрополье бройлеры”, «Пятигорский», «Акашевская тавык фабрикасы» ширкәтләре, «Халитов», “Хисмәтуллин” шәхси предприятиеләре “Хәләл” стандарты буенча комитеттан һәм “Тест – Татарстан” үзәгеннән яңа сертификатлар алган.

Комитет сертификация вакыты чыккан, әмма яңадан тикшерү үтмәгән «Еманжелинск-икмәк”, «Лакомка», «Самараның икенче икмәк пешерү заводы», «Әл Бәрака» предприятиеләрен исемлектән төшереп калдырган дип хәбәр итте “Татар-информ”.

### ИСКЕШӘҺӘР ТАТАРЛАРЫ МӘДӘНИ ЙОРТ ТӨЗЕРГӘ ТЕЛИ

*Төркиянең Искешәһәр татар җәмгыяте мәдәни йорт булдырырга тели. Искешәһәр татар җәмгыяте рәисе Абдулвахит Ирден Татарстан президенты Рөстәм Миңнехановтан бу эшләрдә ярдәм сорый.*



Бу көннәрдә Абдулвахит Ирден татар конгрессы рәисе Ринат Закиров белән очрашты. Анда Ирден әфәнде Искешәһәрдә яшәүче татарларның милли тормышлары турында тәфсилләп сөйләп, киләчәккә планнары белән бүлеште, диелә конгресс сайтында.

Шулай ук җәмгыять шушы арада татар теле курслары ачып җибәргән. Абдулвахит Ирден сүзләренә караганда, теләк белдереп йөрүчеләр күп булса да, җәмгыятьнең үз бинасы булмау сәбәпле, бөтен кешене дә сыйдыра алмыйлар икән. Хәзер инде җәмгыять рәисе Искешәһәрдә татар мәдәни йорты булдыру артыннан йөри башлаган. Ринат Закиров бу мәсьәләне контрольгә алачагын әйтте.

Август аенда узачак татар яшьләре форумында Искешәһәрдән ике делагат катнашачак.

лыгын өмет итеп, ризыктан, хәләл икмәкләрдән тыелабыз.
Барчабызның да, элекке елларда әби-бабаларыбыз ничек озын көннәрдә, кырларда урак урганда, урманнарда агач кискәндә ураза тотканнарын сөйләгәннәрен ишеткәнебез бар. Алар шушы авыр, газаплы эшләрдә булып та, Аллаһы кушканны калдырмаганнар. Ул көннәр белән чагыштырганда бүген өстәлләребездә муллык, тормышларыбыз күпкә җиңел. Шуңа күрә шушы бәрәкәтне, Аллаһының рәхмәтен онытмаска, уразаларыбызны калдырмаска, ай дәвамында игелек һәм изгелек кылырга, нәфесебезне йөгәнләп, Раббыбызның әмерен үтәргә тырышыйк. Гаиләләребездә, урам-авылларыбызда, шәһәрләребездә яхшылыкка чакырыйк, оят һәм гөнаһның ни икәненә төшеник. Ел дәвамында көтеп алынган уразаларыбызны, мөбарәк ай Рамазанны кадерлик, хөрмәтлик. Олысы – кечесенә, яше –картына, бабасы – оныгына, атасы – улына, анасы – кызына, Аллаһының кануннарын, тәртип-әхлакны җиткерергә тырышыйк. Аллаһ Раббыбыз тоткан уразаларыбызны кабул итсен!
**“Нәсыйхәт” газетасы коллективы**

# ТӘРБИЯЧЕБЕЗ КИЛДЕ

**Бер ел буе сагынылган кунак аебыз Рамазан да килеп җитте. Бу айны Аллаһы Тәгалә башкаларыннан үзгә иткән. Пәйгамбәребез дә (с.г.в.): “Рәҗәб–Аллаһның ае, Шәгъбән–минем аем, Рамазан исә, өммәтемнең аедыр”,–дип әйтеп калдырган.**

Һәр мөселман өчен аерылып, әйтеп бетергесез рәхәтлек биреп тора ул. Бу айда бер-беребез белән тагын да якынаябыз, туганнарга, күрше-күләнгә, дусларга ифтар ашларына йөрешәбез. Ифтарга җыелгач, авыз ачканчы җәмәгать белән салаватлар әйтәсең, Коръән тыңлап, төрле гыйбрәтле хикәятләр ишетәсең. Алдагы елда ашта ишеткән бер гыйбрәтле хикәятне сезгә дә сөйлим әле.
Бер шәкертне укытучысы башкаларына караганда ныграк ярата икән. Башка шәкертләр аптырап, укытучыдан моның сәбәбен сорыйлар. Укытучы бөтенесенә дә тавык суеп алып килергә куша. Әмма дә ләкин бер шарт белән: ”Сезнең тавык суйганыгызны да, чистартканыгызны да, миңа алып килгәнегезне дә беркем дә күрергә дә, белергә дә тиеш түгел!”–ди. Шәкертләр ризалашып, барысын да укытучы кушканча үтәп, иртәгесен тавыкларын алып киләләр. Теге шәкерт тавыкны тере килеш алып килә. Укытучы нишләп суеп алып килмәве турында сорагач: ”Кеше күрмәсә дә, мине Аллаһы Тәгалә күреп тора. Шуның өчен тавыкны суймыйча гына алып килдем”, –ди. Укытучы шәкертләренә: ”Менә шуның өчен аны сезгә караганда катырак яратам”,–дип, баштагы сорауларына җавап бирә.
Шушы хикәяттәге кебек, уразада алдыбызда нинди генә тәмле тәгамнәр булса да, тыелып торабыз. Әле Рамазан ае үтеп киткәч тә, ризыкка үреләсең дә, алмыйча торасың бит. Сабыр булырга өйрәтә бу ай. Әле күпме вакытыбызга экономия да ясыйбыз. Төрле рецептлар буенча шуларны пешереп, авыз итеп, табак-савыт юып кына да күпме вакытыбыз үтә бит=)).
Рамазан аеның тагын бер рәхәте–җыелышып тәравих намазларына йөрү. Әбиләр, бабайлар, аларга караганда бигрәк тә балалар, яшьләр яратып йөри бу намазларга. Төрле мәчетләрдә төрлечә укыйлар тәравих намазын. Зур шәһәрләрдә тәравихта Рамазан ае буена тулы бер Коръән укып чыгалар. Ә авылларда көн дә билгеле бер сүрәләрне укыйлар. Коръән сүрәләрен тыңлагач, җанга тынычлык урнаша, ди әби-бабайлар. Тәравих сүзенең тамыры “ра-вә-ха” –ял дигәнне аңлата. Чыннан да, бер ай буе мәчетләрдә рухи азык алып, ял итеп кайтасың.
Бик күпләр динебезгә ураза тота башлау аша киләләр, чөнки ураза көчле рух тәрбияли. Пәйгамбәребез (с.г.в): ”Кем дә кем шушы айның изгелегенә ышанып, бары тик Аллаһ ризалыгы өчен генә Рамазан ае уразасын тотып кабул булса, барлык кылган гөнаһлары да кичереләчәк,”–диде. **(Бухари.Иман,28; Саум,6).**
Бары тик шушы ай белән генә чикләнеп калмыйча, башка айларда да изгелекләрне еш кылыйк. Бер-беребез белән дус яшик. Иншә Аллаһ тоткан уразаларыбыз кабул булып, шушы бер ай буе безне тәрбияләгән тәрбиячебезне икенче елга да сөенеп каршы алырга насыйп булсын.

**СӨМБЕЛ ШӘРИФУЛЛИНА,**
**Казан Федераль Университеты талибәсе**

## МАТБУГАТ КОНФЕРЕНЦИЯСЕНДӘ

*18 июльдә Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте бинасында мөфти Илдус хәзрәт Фәиз һәм аппарат җитәкчесе Ришат Хәмидуллин катнашында журналистлар өчен матбугат конференциясе үткәрелде. Әлеге чара изге Рамазан аена багышланып уздырылды.*



Илдус хәзрәтнең сөйләвенчә, быелгы Рамазан ае 20 июльдә башлана, ә тәүге Тәравих намазы 19ында ястүдән соң укыла. “Рамазан аеның башлану көненә килгәндә, аны казыйлар һәм Голәмәләр шурасы ныклап өйрәнде һәм аларның тәкъдиме, обсерваториядән алынган мәгълүматлар нигезендә, мөфти бирде. Монда Төркия, Согуд Гарәбстаны кебек мөселман илләреннән килгән хәбәрләр дә тикшерелде. Алар да нәкъ шушы көнне уразага керә. Аннары мөфти хәзрәтләре быелгы фитыр сәдакасының күләме бер кешегә 50 сумнан 300 сумга кадәр дип билгеләнүен хәбәр итте. 50 сумы иң кимендә дип алынган, аны уртача хәлле мөселманнар түли, ә керемнәре югарырак булганнар фитыр сәдакасын җан башына хәтта 300 сумнан да бирә ала. Ураза бәйрәменә хәтле (гаеткә кадәр) бер сабый бала дөньяга аваз салса, фитыр сәдакасы аның өчен дә түләнә. Фитыр сәдакасын гаилә башлыгы, ягъни ир кеше түли, тик биредә аның балаларының үз милке булуы яисә булмавы исәпкә алына. Фитыр сәдакасы ярлыларга, ятимнәргә – кереме аз булганнарга бирелә.
Зәкят сәдакасын шулай ук Рамазан аенда тапшыру хәерле булып санала. Ул ел әйләнәсендә берәүнең 130 мең сум акчасы булса, шуннан чыгып исәпләнә. Әлеге байлыкка ия булучы кеше бу сумманың кырыктан бер өлешен, ягъни 3250 сумын зәкят итеп фәкыйрьләргә, мәдрәсәдә укучы шәкертләргә - мохтаҗларга тапшыра ала.
Быелгы Тәравих намазы мәчетләрдә 20 рәкәгать итеп укылачак. Әгәр бер мөселманның сәламәтлеге начар булса, ул Тәравихны киметеп, 8 рәкәгать итеп укырга да мөмкин. Журналистлар мөфтигә шактый сораулар да бирделәр. Аларның берсе республика күләмендә үткәрелә торган ифтарга кагылышлы иде. Илдус хәзрәт быел да мондый ифтарны, ягъни авыз ачу мәҗлесен уздырырга җыенулары, аның Коръән индерелә башлаган Кадер кичәсе тирәсендә булачагы турында хәбәр бирде. “Мөселманнарга быелгы уразаны тоту җиңел булмаячак, чөнки эссе көннәрдә 17-18 сәгать ач торырга кирәк була. Шулай да кардәшләребез зур сабырлык һәм түземлелек, барлык җан ияләренә рәхим-шәфкатьлелек күрсәтеп, начар сүзләрдән, әшәке уй-фикерләрдән тыелып, нәфесебезне тыеп яшәрләр дип уйлыйм. Хак Тәгалә безнең тоткан уразаларыбызны кабул кылып, аңа тиешле әҗер-савапларын да Үзе бирер, Аллаһы боерса”,– диде Илдус хәзрәт Фәиз.

**http://www.tatar-islam.com сайтыннан кыскартылып алынды**

## Сорау-җавап

# Уразада туклану

**Рамазан аенда ризыклануга багышланган нинди дә булса тәкъдимнәр бармы?**

Бер хәдистә бу хакта берничә файдалы тәкъдим бар.



«Уразаны тотучы кешегә көч бирүдә кулланыла торган 3 тәҗрибә бар: 1) башта ашарга, аннары эчәргә кирәк (ашаганда күп эчмәскә, ашказаны согын сыеклатмаска, ризык кулланып, 40-60 минут узгач кына эчәргә), 2) сәхәр вакытында азыкны куллану, 3) көндез йоклап алырга (13.00 -16.00 сәгать арасында 20-40 минут һәм аннан күбрәк черем итәргә)». Бу хәдиснең соңнәткә туры килгән беренче пунктының асылы шуннан гыйбарәт: кеше, мәсәлән, кичке авыз ачу вакытында беренче эш итеп су эчә һәм берничә хөрмә ашый. Аннары кичке намазны укый, соңрак ашый. Беренче итеп су эчү ашказаныэчәкләрне юдырырга ярдәм итә. Сүз уңаеннан, ач карынга җылы су эчү файдалы. Аңа бераз бал да кушып җибәрсәгез була. Хәдистә ифтар вакытында ризык кабул иткәч, аны сыеклату белән мавыгырга тәкъдим ителми. Бер үк вакытта күп итеп ашау һәм эчү нәтиҗәсендә ашказанында ризыкны эшкәртү кыенлаша (ашказаны согы сыеклана), бу исә ризыкның эшкәртелеп бетмәвенә китерә, сару кайный башлый. Ураза вакытында бу кайбер кыенлыклар китереп чыгара: кичтән кабул ителгән ризык эшкәртелеп бетми, иртәнге якта кеше йә бөтенләй ашамый, чөнки ачыкмаган була, ашаса, инде ризык өстенә ризык кабул иткән булып чыга. Ә бу исә көтелгән нәтиҗәгә китерми. Мөселманнар кич белән һәм иртәнге якта, ягъни авыз ачканда, сәхәр вакытында артык ризык кулланудан саклансыннар иде. Кызганыч ки, иманнары ныгып җитмәгән кайберәүләр ачлыктан куркып калып, күп ризык ашыйлар. Бу аларга көн дәвамында күтәренке кәефне сакларга булышыр, дип уйлап ялгышалар. Организмына күп ризык керткән кеше үзе өчен гадәти булмаган, кыен хәлдә кала: бихисап авыр ризыкны эшкәртү өчен аның бөтен көндез тупланган энергиясе китә, шуңа күрә икенче көнне андый затлар йокылыуяулы, арган кыяфәтле, «Аллаһ ризалыгы хакына үз-үзен интектерүче»гә әйләнә. Күпләр шулай эшли һәм бу Раббыбыз нигъмәтләреннән дөрес файдаланмау булып тора. Мин кич белән салатларга, җиләк-җимеш, яшелчәләргә басым ясарга, ә иртән ботка, кипкән җимеш һәм чикләвекләр ашарга киңәш итәр идем.

Кеше үзгәрә һәм һәр көнне токкан уразасы аны үзгәртә. Әгәр ул үзенә җитәрлек дәрәҗәдә генә көненә ике тапкыр ризык кулланса, суны шулай ук җитәрлек дәрәҗәдә эчсә, 7 сәгатьтән дә кимрәк, 8 сәгатьтән дә күбрәк йокламаса, физик күнегүләр ясарга иренмәсә (5-6 чакрымны җәяү йөрсә, йөзү белән шөгыльләнсә, җиңелчә йөгерсә), аның токкан уразалары файдага булыр дип уйлыйм. Бередә иң мөһиме–уразаны Аллаһ ризалыгы өчен дип тоту.

**Ураза тотучы кеше төнге сменада эшли, ә көндезен йоклап уздыра. Ул Аллаһ тарафыннан көндезләрен актив үткәргән кеше кебек үк бүләк алачыкмы?**

Әгәр аның эш графигы шундый икән, әлбәттә, ул шундый ук бүләк алыр. Шунысын исегезгә төшерәм: тәүлегенә 8 сәгатьтән артык, 7 сәгатьтән ким йоклау зыянлы.

**Сорауларга Мәскәүнең Мемориаль мәчете имамы Шамил хәзрәт ГАЛӘВЕТДИН җавап бирде**

## Намаз вакытлары

| Көне | Сәхәр тәмам | Иртәнге намаз | Кояш чыгу | Икенде | Ахшам намазы, авыз ачу | Ясту намазы, тәравих |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 19 | | 2.56 | 4.26 | 18.29 | 21.13 | 22.43 |
| 20 | 2.28 | 2.58 | 4.28 | 18.28 | 21.11 | 22.41 |
| 21 | 2.29 | 2.59 | 4.29 | 18.27 | 21.09 | 22.39 |
| 22 | 2.31 | 3.01 | 4.31 | 18.26 | 21.08 | 22.38 |
| 23 | 2.33 | 3.03 | 4.33 | 18.25 | 21.06 | 22.36 |
| 24 | 2.34 | 3.04 | 4.34 | 18.23 | 21.04 | 22.34 |
| 25 | 2.36 | 3.06 | 4.36 | 18.23 | 21.03 | 22.33 |
| 26 | 2.38 | 3.08 | 4.38 | 18.21 | 21.01 | 22.31 |
| 27 | 2.40 | 3.10 | 4.40 | 18.20 | 20.59 | 22.29 |
| 28 | 2.41 | 3.11 | 4.41 | 18.19 | 20.57 | 22.27 |
| 29 | 2.43 | 3.13 | 4.43 | 18.17 | 20.55 | 22.25 |
| 30 | 2.45 | 3.15 | 4.45 | 18.16 | 20.53 | 22.23 |
| 31 | 2.47 | 3.17 | 4.47 | 18.15 | 20.51 | 22.21 |
| 1 | 2.49 | 3.19 | 4.47 | 18.13 | 20.49 | 22.19 |
| 2 | 2.51 | 3.21 | 4.51 | 18.12 | 20.47 | 22.17 |
| 3 | 2.53 | 3.23 | 4.53 | 18.11 | 20.45 | 22.15 |
| 4 | 2.55 | 3.25 | 4.55 | 18.09 | 20.43 | 22.13 |
| 5 | 2.56 | 3.26 | 4.56 | 18.08 | 20.41 | 22.11 |
| 6 | 2.58 | 3.28 | 4.58 | 18.07 | 20.39 | 22.09 |
| 7 | 3.00 | 3.30 | 5.00 | 18.05 | 20.37 | 22.07 |
| 8 | 3.02 | 3.32 | 5.02 | 18.04 | 20.35 | 22.05 |
| 9 | 3.04 | 3.34 | 5.04 | 18.02 | 20.32 | 22.05 |
| 10 | 3.06 | 3.36 | 5.06 | 18.01 | 20.30 | 22.00 |
| 11 | 3.08 | 3.38 | 5.08 | 17.59 | 20.28 | 21.58 |
| 12 | 3.10 | 3.40 | 5.10 | 17.58 | 20.26 | 21.56 |
| 13 | 3.12 | 3.42 | 5.12 | 17.56 | 20.23 | 21.53 |
| 14 | 3.14 | 3.44 | 5.14 | 17.55 | 20.21 | 21.51 |
| 15 | 3.16 | 3.46 | 5.16 | 17.53 | 20.19 | 21.49 |
| 16 | 3.18 | 3.48 | 5.18 | 17.51 | 20.16 | 21.46 |
| 17 | 3.20 | 3.50 | 5.20 | 17.50 | 20.14 | 21.44 |
| 18 | 3.22 | 3.52 | 5.22 | 17.49 | 20.12 | 21.42 |

*Искәрмә. Өйлә намазы–13 сәгать 2 минутта*

## Укырга чакырабыз

# Мамадыш мәдрәсәсенә рәхим итегез!

Татарстан Җөмһүрияте Мөселманнары Дания Нәзарәте каршындагы Мамадыш мәдрәсәсе 2012-2013 уку елына шәкертләр туплый.

Белгечләр әзерләү көндезге һәм кичке уку рәвешендә алып барыла.

Көндезге бүлеккә яше 14тән дә ким булмаган егетләр кабул ителә. Шәкертләр мәдрәсә тулай торагында яшәү урыны һәм көненә өч тапкыр ашау-эчү белән тәэмин ителәләр. Уку вакыты – өч ел. Урта белем алу икенче санлы лицей базасында алып барыла. Мәдрәсәне тәмамлаганнан соң шәкертләргә квалификация комиссиясе карары нигезендә тиешле белгечлек алу турында диплом бирелә.

Укырга керү өчен кабул итү комиссиясенә түбәндәге документларны тапшырырга кирәк:

**1) Гариза. 2) Белем турында таныклык. 3) 086-формасында сәламәтлек турында белешмә. 4) Паспорт (копия). 5) 3х4 үлчәмендә 4 фотосурәт. 6) №26 формасында шәхси медицина картасы**

**Документлар 30 августка кадәр кабул ителә.**

*Намаз укырга өйрәнергә һәм дин белемен үзләштерергә теләүчеләр өчен мәдрәсәдә кичке уку бүлеге һәм читтән торып уку бүлеге эшли. Бу бүлекләргә хатын-кызлар һәм ир-егетләр кабул ителә. Яшь чиге куелмаган.*

*Безнең адрес: Татарстан Республикасы, Мамадыш шәһәре, М. Җәлил урамы 8/28,*

**Телефоннар: 3-19-17, 89172802391**

**Газетада Аллаһы Тәгаләнең Бөек исемнәре булганга күрә, аны саклап тотуыгыз сорала**

**Баш мөхәррир: Хәбибуллин А.М. Мөхәррир урынбасары: Хәбибуллина Э.Р.**
**Дизайн һәм верстка: Мингалиева Ф.Н. Җаваплы сәркатип: Спиридонова А.С.**
**Безнең адрес: Мамадыш шәһәре, Муса Җәлил урамы,8/28. mamadysh-medrese@mail.ru. Газета “Татмедиа” ААҖнең Мамадыш муниципаль районы”Нократ” мәгълүмат-матбугат филиалында басылды. Тираж татар телендә 125 данә.**